instagram.com/kyzyl_tan/ vk.com/club32350601 ok.ru/group/53072966582336



## СТӘРЛЕТАМАК НИЧЕК ЯШИ?

(⇨ Башы 1нче биттә).

**Курчатов урамында**гы күпфатирлы йортлар ихатасында Радий Хәбиров “Башкортстан ихаталары” программасын гамәлгә ашыру барышы белән танышты.

Төбәк җитәкчесе белән фикер алышканда урындагы халык территорияне төзекләндерү буенча теләк-тәкъдимнәрен әйтте. Стәрлетамакта быел барлыгы 40 күпфатирлы йортның 18 ихатасы төзекләндереләчәк. Бу максатларга 130 миллион сумга якын акча бүленгән.

2005 елда Бөек Җиңүнең 60 еллыгына ачылган **Советлар Союзы маршалы Г. К. Жуков исемендәге сквер** – парк зоналарын яңартуның яхшы үрнәге булып тора. Монда Стәрлетамакта туып-үскән һәм сугышта һәлак булган һәм Советлар Союзы Геройлары исемен алган стәрлетамаклыларның бюстлары урнашкан “Стена” монументы куелган. Радий Хәбиров быел шәһәр паркларының кайсылары төзекләндереләчәге белән кызыксынды.

Шәһәрнең **Көнбатыш торак районы**ның 4А микрорайонында төзелүче 2нче йорт дольщиклары белән Радий Хәбиров объект төзелешен тәмамлау һәм аларның хокукларын тергезү перспективалары турында фикер алышты.

Агымдагы елда Стәрлетамакта күпфатирлы 83 йортның 355 подъездын ремонтлау өчен 137 миллион сум тотынылачак. Программаны гамәлгә ашыру барышы белән Радий Хәбиров **Артем урамында**гы 21А күпфатирлы йортның подъездларын карап чыгып танышты.

Арытаба Радий Хәбиров 1 июльдә эшли башлаган **сөт фабрика-кухнясы**нда булды. Ул Уфадан соң республикада махсуслашкан балалар туклануы учреждениесенең икенчесе. Хәзер аның продукциясе белән Стәрлетамак, Мәләвез, Ишембай районнарында, шулай ук Стәрлетамак һәм Салават шәһәрләрендә яшәүче балалар тәэмин ителә. Моның өчен муниципалитетларда продукция бирүнең җиде урыны оештырылган. Моннан тыш, продукция белән Күмертау шәһәре һәм Авыргазы районын тәэмин итү мәсьәләсе карала.

Эш сәфәре барышында Радий Хәбиров икмәк һәм икмәк – күмәч пешерү буенча республиканың күптәнге предприятиеләренең берсе – быел үзенең 110 еллыгын бәйрәм итәчәк **Стәрлетамак икмәк комбинатында** булды. Радий Хәбиров комбинат җитәкчелеге белән җитештерүне арытаба үстерү перспективалары һәм кирәкле ярдәм юнәлешләре турында фикер алышты.

Шәһәрнең тарихи өлешендә Радий Хәбиров Стәрлетамакның җәмәгать территорияләре арасында халык күпләп йөрү буенча беренче урында торган **“Иске шәһәр” ял итү зонасы**н карады.

**Үз хәбәрчебез.**

## ЯЗГЫ СЕССИЯГӘ ЙОМГАК ЯСАЛДЫ

**9 июльдә Дәүләт җыелышы-Корылтай Рәисе Константин Толкачев матбугат конференциясе үткәрде. Парламент Рәисе республика депутатлар корпусының язгы сессия чорында башкарылган эш нәтиҗәләре, якын арада көченә керәчәк актуаль законнар, башка төбәкләр һәм илләр белән парламентара хезмәттәшлек, Русия Дәүләт думасына кертелгән федераль закон проектлары, быел көзгә Дәүләт җыелышы-Корылтайның эш планнары турында сөйләде.**

— Агымдагы елның гыйнвар-июль айларында алтынчы чакырылыш Дәүләт җыелышы-Корылтай депутатлары 90нан артык закон кабул итте. Республика закон нормаларын камилләштерү максатында Дәүләт җыелышы-Корылтай һәм аның даими комитетлары тарафыннан 3 парламент тыңлаулары, 13 “түгәрәк өстәл” үтте, дәүләт власте органнары вәкилләре һәм учреждениеләр җитәкчеләренең закон үтәлеше турындагы 30дан артык мәгълүматы тыңланды, — диде Константин Борисович.

Елның беренче яртысы йомгаклары буенча Дәүләт җыелышы-Корылтай чираттагы тапкыр Русия парламентына кертелгән һәм федераль закон статусын алган закон чыгару башлангычлары саны буенча ил төбәкләре парламентлары арасында беренче урында.

Язгы сессия чорында кабул ителгән иң актуаль республика законнары арасында Константин Толкачев “Башкортстан Республикасында этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә эшчәнлекне җайга салу һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчү) чикләү турында”гы Законга кертелгән төзәтмәләрне атады. Аларга ярашлы, Яшьләр көнендә (27 июнь), Белем көнендә (1 сентябрь яки 2 сентябрь) һәм Сабантуйлар үткәрү көнендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны тыю кертелде. Шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сату вакыты кыскартылды. Алкогольне 10 сәгатьтән 22 сәгатькә кадәр (элек – 8дән 23 сәгатькә кадәр) сатарга рөхсәт ителә.

“Административ хокук бозулар турында Башкортстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында”гы Закон транспорт чараларын (аларга тагылмаларны) урнаштыру өчен җаваплылыкны билгели торган 6.21 яңа статья белән тулыландырды. Административ комиссияләр әгъзаларына актлар төзү һәм административ эшләрне карау буенча вәкаләтләр бирелде.

Язгы сессия чорында депутатлар кабул иткән тагын бер мөһим закон “Башкортстан Республикасында Мәгариф турында” Башкортстан Республикасы Законының 8 статьясына төзәтмәләр кертелде. Документ нигезендә барлык гаиләләр дә балалар бакчалары өчен түләү компенсациясенә хокук алды.

– Мохтаҗлык критерие бетерелә, – диде парламент спикеры. – Компенсация, керем дәрәҗәсенә карап, барлык гаиләләргә дә түләнәчәк. Мондый ярдәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның максималь санын колачларга мөмкинлек бирә, демографик хәлгә уңай йогынты ясый, күп гаиләләр өчен, бигрәк тә авылда мөһим.

Республика халкының депутатлар белән хезмәттәшлеге Дәүләт җыелышы-Корылтай сайтында электрон кабул итү ярдәмендә башкарыла. Бу ресурс ярдәмендә теләгән һәркем мөрәҗәгать калдыра һәм аны тикшерү барышын күзәтә ала.

**Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.**

*Икътисади күзәтү*

# ҮСЕШ ЮЛЫНА ЧЫККАНДА МӨҺИМ АДЫМ

### Башкортстанның көндәшлеген арттыру – өстенлекле бурыч

**Русия Президенты Владимир Путинның “2024 елга кадәр Русия Федерациясен үстерүнең гомумдәүләт максатлары һәм стратегик бурычлары турында”гы Указына ярашлы кабул ителгән гомумдәүләт проектлары ил икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре санала. Алар арасында демография, сәламәтлек саклау, мәгариф, фән, хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә, кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү, халыкара кооперация һәм экспортны үстерү, хәвефсез һәм сыйфатлы автомобиль юллары, санлы икътисад, мәдәният, экология, торак һәм шәһәр мохите кебек юнәлешләр бар. Мәсәлән, “Халыкара кооперация һәм экспортны үстерү” проекты Башкортстанның көндәшлеген арттыруда, аны яңача үсеш юлына чыгаруда мөһим адым булып тора.**



Гомумән, бүгенге шартларда дөньядагы тенденцияләрне исәпкә алып, тышкы сәүдә мөмкинлекләрен, икътисади элемтәләрне нәтиҗәле итеп файдаланып кына республика икътисадының көндәшлек сәләтен үстерергә мөмкин.

Билгеле булуынча, Башкортстанның тышкы икътисади эшчәнлек белән бәйле керем-табышы әлеге вакытта, башка төбәкләр белән чагыштырганда югарырак булса да, саннар республиканың икътисади потенциалына туры килми. Беренчедән, дөнья базарына без нигездә яңа технологияләргә нигезләнгән товарларга караганда, чималны күбрәк чыгарабыз. Икенче¬дән, игълан ителгән халыкара санкцияләр республиканың тышкы икътисади эшчәнлегенә тискәре йогынты ясамый калмый.

Башкортстанны ил күләмендә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә дә таныту, аның потенциалын аңлату, үзара файдалы хезмәттәшлек өчен уңайлы партнерлар табу тиз арада гына башкарып чыга торган эшләр түгел. Ничек кенә булмасын, соңгы вакытта республика җитәкчелегенең бу өлкәләрдәге эшчәнлекне активлаштыруы аерым игътибарга лаек.

17 июльдә Уфаның “Торатау” Конгресс-холлында “Экспортлау чоры” дип исемләнгән форум ачылачак. Анда “Халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү” гомумдәүләт проектын тормышка ашыру буенча фикер алышачаклар. Шулай ук экспортерларны борчыган мәсьәләләр һәм экспортка юнәлеш тоткан предприятиеләр проблемалары тикшереләчәк. Форумда РФ Хөкүмәте вице-премьеры, финанс министры Антон Силуанов, “Русия экспорт үзәге” җәмгыятенең генеральный директоры Андрей Слепнев һәм башка дәрәҗәле вәкилләр катнашуы көтелә.

Узган атнада Республика йортында Башкортстан Башлыгы Хакимияте җитәкчесе Александр Сидякин рәислегендә инвестиция һәм эшкуарлык мохитен яхшыртуга багышланган чираттагы утырыш булды. Анда “Халыкара кооперацияне һәм экспортны үстерү” гомумдәүләт проектын гамәлгә куюның көнүзәк бурычлары да тикшерелде. Аеруча экспортка юнәлеш тоткан кече һәм урта малтабарлык субъектларына ярдәмне нәтиҗәле итеп оештыруның юллары билгеләнде. “Гомумдәүләт проектының максаты – экспортны үстерү системасын камилләштерү, республика продукциясен сату базарларын киңәйтү һәм җитештерүчеләрне экспорт эшчәнлегенә җәлеп итүне үстерү исәбенә, Башкортстанда товар җитештерүчеләрнең чимал булмаган продукциясе экспорты күләмен арттыруга ирешү,” дип билгеләнде утырышта.

Гомумдәүләт проектларына ил буенча 25 триллион сум акча сарыф ителәчәк.

Хәбәр ителүенчә, авыл хуҗалыгы продукциясе белән Башкортстан үзен тулысынча тәэмин итә. Ул гына да түгел, республика чит төбәкләргә дә байтак күләмдә азык-төлек сата. Атап әйткәндә, ашлык, ит, кош ите, сөт үз ихтыяҗларыбызга караганда күбрәк җитештерелә. Башкортстан атап әйткәндә Иран, Мисыр, Төркия, Израиль, Әзербайҗан, Бангладеш, Германия, Латвия, Бельгия, Сөгуд Гарәбстаны, Литва, Шри-Ланка, Монголия, Белоруссия, Казахстанга үз продукциясен озата. Узган ел, мәсәлән, азык-төлек экспорты күләме барлыгы 76,3 миллион долларлык булса, агымдагы елда аны 91 миллионга җиткерү максаты куелды. Ә инде 2024 елда Башкортстан 230 миллион долларлык продукция сатуга исәп тота.

**Идрис СӘЕТГАЛИЕВ.**

*Сайлау-2019*

# Тулысынча законнарга нигезләнә

**Билгеле булуынча, 8 сентябрь — Бердәм тавыш бирү көнендә Башкортстан Башлыгы сайланачак. Әлеге вакытта бу чарага җитди әзерлек бара. Сайлау алды кампаниясе нинди хокукый базаларга нигезләнеп үткәрелә? Шушы һәм башка сораулар белән республиканың Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары Марат Гадиловка мөрәҗәгать иттек.**

**— Марат Венерович, республика Башлыгы вазыйфасына кандидатларның агитация вакыты кайчан башлана һәм ул ничек башкарылырга тиеш?**

— Әлеге вазыйфага агитация кандидатның сайлау комиссиясенә гариза тапшырган көнендә, ә киңкүләм мәгълүмат чараларында сайлаулардан 28 көн алда, ягъни бу юлы ул 2019 елның 10 августында башлана. Агитация сайлау көнен каршылаганда төнге 12 сәгатьтә тәмамланырга тиеш.

Кандидат агитация эшләрен үзе теләгәнчә башкара ала. Шул ук вакытта, сайлауларга һәм агитациягә кагылышлы законнарга таянып, башка кешеләрне бу эшкә җәлеп итәргә хокуклы.

**— Билгеле, сайлау алды кампаниясе бик зур чыгымнар таләп итә. Бу чыгымнарны кем каплый һәм аның ниндидер билгеләнгән күләме бармы?**

— Сайлау алды агитациясен тулысынча сайлау фонды каплый. Башкортстан Республикасы Сайлаулар турында кодексының икенче бүлеге, 95.5 статьясына ярашлы, республика Башлыгын сайлаулар өчен сайлау фондындагы акча 200 миллион сумнан күбрәк булмаска тиеш. Шул ук вакытта, әлеге кандидатны тәкъдим иткән партия сайлау фонды аша бу кандидатның сайлау кампаниясендәге чыгымнарын тулысынча үз өстенә алырга хокуклы. Сайлау фонды кандидатның үз акчасыннан яисә гражданнарның үз теләкләре белән керткән өлешеннән барлыкка килергә мөмкин.

**— Агитация материалларында нинди мәгълүматлар булырга һәм ул нинди урыннарда таратылырга тиеш?**

— Тәүдә агитация материаллары республиканың Үзәк сайлау комиссиясенә тикшерү өчен тәкъдим ителә. Анда экстремизмга әйдәүне хәтерләткән мәгълүмат булмаска тиеш. Шулай ук биредә материалларны әзерләгәндә сайлауларга кагылышлы Русия Федерациясе законнары үтәлгәнме, аларны бастыру чыгымнары хокукый базага туры киләме һәм башка үзенчәлекләргә игътибар ителә. Әгәр дә ниндидер закон бозу очраклары табыла икән, комиссия хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итә.

Басылган агитация материаллары сайлау участогы алдында махсус бүленгән урында урнаштырыла. Бу урынны сайлауларга кадәр 30 көн алда урындагы үзидарә билгели. Моннан тыш, агитация материаллары төрле биналарда урныштырылырга мөмкин, әмма моның өчен бинаның хуҗасыннан рөхсәт алу таләп ителә.

Агитация материаллары һәйкәлләрдә, төрле тарихи-мәдәни яисә архитектура биналарына ябыштырылырга тиеш түгел. Бу җәһәттән закон бозучыларга административ җаваплылык каралган.

**Гөлия ГӘРӘЕВА әзерләде.**

## Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына Хәбиров Радий Фәрит улы кандидатурасын теркәү турындагы карары

“Бердәм Русия” Бөтенрусия сәяси партиясе Башкортстан төбәк бүлекчәсенең сайлау берләшмәсе Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидат итеп Радий Фәрит улы Хәбировны тәкъдим итү тәртибе үтәлешен, “Русия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль закон, Башкортстан Республикасының Сайлаулар турында кодексы һәм кандидатны теркәү өчен кирәкле документларның таләпләргә туры килүен тикшереп, Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе түбәндәгене билгеләде.

Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына Хәбиров Радий Фәрит улы кандидатурасын күрсәтү тәртибе, кандидатны теркәү өчен тәкъдим ителгән документларның Башкортстан Республикасы Сайлаулар турында кодексының 40, 46.1 статьялары, 48, 95.3, 95.4 статьяларның 2.1нче кисәге таләпләренә туры килә.

Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең агымдагы елның 30 маендагы “2019 елның 8 сентябрендәге Башкортстан Республикасы Башлыгын сайлауларда Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидатны хуплау өчен тиешле кешеләр саны һәм кандидатны хуплаган депутатлар караган муниципаль район һәм шәһәр округлары саны турында” 88/1-6 санлы карарына ярашлы, Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидатны теркәү өчен Башкортстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкаләтле органнары депутатларының 454 имзасын, шул исәптән, Башкортстан Республикасының 48 муниципаль район һәм шәһәр округларында җыелган вәкаләтле органнары депутатларының муниципаль район һәм шәһәр округлары вәкаләтле органнары депутатларының 56 имзасын җыярга кирәк. Әлеге карар нигезендә, Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидат Радий Фәрит улы Хәбиров тарафыннан теркәлү өчен муниципаль берәмлекләр вәкаләтле органнары депутатлары имзалары белән кандидатны 476 хуплау кәгазе, шул исәптән, Башкортстан Республикасының 49 муниципаль район һәм шәһәр округлары депутатлары култамгалары белән нығытылган 58 хуплау кәгазе тәкъдим ителде.

Кандидатны хуплау кәгазьләрен тикшерү барышында югарыда күрсәтелгән 476 имзаның чын булуы билгеләнде. Шулай итеп, Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидат Радий Фәрит улы Хәбировның Башкортстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкаләтле органнары депутатларының җитәрлек санда ышанычлы имзалары тәкъдим ителде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, “Русия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 38 статьясына, Башкортстан Республикасы Сайлаулар турында кодексының 51 статьясына таянып, Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карар итә:

1. “Бердәм Русия” Бөтенрусия сәяси партиясенең Башкортстан төбәк бүлекчәсе сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән 1964 елда туган Радий Фәрит улы Хәбировны агымдагы елның 8 июлендә 14 сәгать 20 минутта Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидат итеп теркәргә.
2. Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына теркәлгән кандидат Радий Фәрит улы Хәбировка билгеләнгән үрнәктә теркәү турында таныклык бирергә.
3. Әлеге карарны “Республика Башкортостан”, “Башкортостан”, “Кызыл таң” гәзитләрендә бастырырга.

**Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе И. А. МАКАРЕНКО.**
**Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре М. Б. ДОЛМАТОВА.**

8 июль, 2019 ел.
№101/1-6.

Издательство “Кызыл таң” — филиал ГУП РБ Издательский дом “Республика Башкортостан”. Учредители республиканской общественно-политической газеты “Кызыл таң” — Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года. Выходит во вторник, четверг и пятницу на татарском языке.

Баш мөхәррир
Фаил Камил улы ФӘТХЕТДИНОВ.
Мөхәрририят:
**Илдар Фазлетдинов** (җаваплы секретарь), **Фәнис Гәрәев, Резеда Нуртдинова, Рәфис Сәяхов**, **Олег Төхвәтуллин** (баш мөхәррир урынбасарлары), **Фәрит Фаткуллин.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
450079, БР, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы,13, 6нчы кат.
Адрес редакции и издателя:
450079, РБ, Уфа,
ул. 50-летия Октября,13,
6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 4 басма табак
Гомум тиражы — 4773 данә
Заказ № 1115.

Гәзит “Кызыл таң” нәшриятының компьютер цехында җыелды һәм Нефтекама матбугат йорты типографиясендә басылды:
452680, БР, Нефтекама шәһәре,
Березовка шоссесы, 4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.
Газета отпечатана в типографии Нефтекамского дома печати.
452680, РБ, г. Нефтекамск,
Березовское шоссе,4А,
тел. (8-34783) 7-07-57.

Телефоннар:

| | |
|---|---|
| Кабул итү бүлмәсе — | 272-13-61 |
| баш мөхәррир урынбасарлары — | 272-97-71; 273-50-56 |
| җаваплы секретарь — | 272-74-05 |
| Бүлекләр: | |
| сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — | 272-58-40 |
| әдәбият һәм сәнгать — | 272-35-22 |
| авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — | 273-46-19 |
| яңалыклар — | 272-75-68 |
| хатлар һәм социаль мәсьәләләр — | 272-82-07 |
| рәссам — | 272-75-21 |
| реклама — | 272-62-27 |
| маркетинг — | 272-35-70 |
| бухгалтерия — | 273-43-43 |
| тәрҗемәчеләр — | 272-74-52 |
| “Әллүки” журналы — | 272-62-19 |
| “Тулпар” журналы — | 272-67-48 |

Факс — 273-88-01, 272-62-27
Үз хәбәрчеләребез:

| | |
|---|---|
| Октябрьский, Бүздәк, Әлшәй, Благовар | 8-937-30-24-087 |
| Борай, Кушнаренко, Дүртөйле | 8-917-80-37-750 |
| Илеш, Бакалы, Шаран | 8-937-49-35-735 |

*Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кульязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация бүлеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.*

*Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.*

“Кызыл таң”ның индексы:
атнага өч тапкыр басылганыныкы — П2760
атнага бер тапкыр — П3408
“Әллүки” журналы — П2712
“Тулпар” журналы — П2715

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
Издательство “Кызыл тан”
филиал ГУП РБ Издательский дом
“Республика Башкортостан”
БАШКИРСКИЙ РФ АО
“РОССЕЛЬХОЗБАНК”
р/с 40602810862000000102
к/с 30101810200000000934
БИК 048073934
ИНН 0278066967
КПП 027843006
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 58.13.1
Дежур: Р. ВӘЛИТОВА,
Л. ЯКУПОВА.

© “Кызыл таң” № 80 (25384). 12+